РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » октябрь 2025ел № 05

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 30 октябрендә 14 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2025 елның 30 октябрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенын үткәрү урыны- Урманай авылы, Татарстан урамы, 27а нче йорт, Урманай авылы мәдәният Йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 17 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган

материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: рманай авылы, Татарстан урамы, 15А нче йорт;

- сайлау хокукына ия булган Урманай торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Урманай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар кору** (зиратка материал сатып алу, киртәне урнаштыру, алмаштыру һәм буяу, тоташ эшли торган гербицид сатып алу һәм химик эшкәртү, үләнне чаптыру, агачларны һәм куакларны кисү, чүп-чарны җыю):

**РИЗА** **КАРШЫ».**

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Э.Р.Абдуллина